**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2017 № 01-02/79

г. Казань

Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/62 номерлы боерыгы белән расланган исемлеген тулыландыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/62 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1 | Әлмәт шәһәре | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Ленин ур., 98 йорт | Ленин урамы буенча «Нефтьче» мәдәният сарае янәшәсендәге 98 нче йорт янындагы территория («Нефтьче» мәйданы) |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Белоглазов ур., 60 йорт | Белоглазов урамы буенча «Юбилейный» спорт сарае янәшәсендәге 60 нчы йорт янындагы территория («Юбилейный» спорт сарае мәйданы) |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Ленин ур., 21б йорт | Ленин урамы буенча яшьләр үзәге (Яшьләр үзәге мәйданы) янәшәсендәге 21б нче йорт янындагы территория |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһәре | шәһәр мәйданы территориясе |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһ., Р. Фәхретдин ур., 13 йорт | Р. Фәхретдин урамы буенча 13 нче йорт янындагы территория (Хәтер мәйданы)». |

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (А.Г.Сафин) әлеге боерыкны “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә (Э.И.Слепнева) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И.Заһидуллин

Килештерүчеләр:

Татарстан Республикасы
юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтов

Норматив хокукый актларны теркәү
һәм Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы эшчәнлеген
хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы Э.И.Слепнева

Җирле үзидарә органнарына
хокукый консультацион-методик
ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы М.А.Пашкова

Боерыкны әзерләде:
Җирле үзидарә органнарына хокукый
консультацион-методик ярдәм күрсәтү
бүлегенең әйдәп баручы советнигы А.Н.Ханеня